Котлы-Бөкәш авыл җирлеге башкарма комитеты
Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы

КАРАР № 44

Котлы-Бөкәш авылы 2016 елның 23 сентябре

Торак мөнәсәбәтләре өлкәсендә аерым
административ регламентларның үз көчләрен
югалтуын тану турында

2015 елның 1 гыйнварыннан авыл җирлекләре территорияләрендә торак мөнәсәбәтләре өлкәсендәге вәкаләтләр муниципаль районнарның җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә кертелүгә бәйле рәвештә, муниципаль норматив хокукый актны законнарга яраклаштыру максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 6 пункты, 3,4 өлеше, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 15 статьясындагы 3,5 өлеше нигезендә, муниципаль норматив хокукый актны законнарга туры китерү, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы « Котлы-Бөкәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставын, Балык Бистәсе районы прокуратурасының 21.09.2016 ел, №02-08-03/2016 Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы-Бөкәш авыл җирлеге Башкарма комитетының 2013 елның 26 ноябрендәге 28 номерлы карарына протестын, нигезендә карар бирәм:

1. - Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы-Бөкәш авыл җирлеге Башкарма комитетының «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2013 елның 21 ноябрендәге 55 номерлы карары белән расланган Торак бинаны үзгәртеп коруга һәм (яки) яңадан планлаштыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын;

- Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы-Бөкәш авыл җирлеге Башкарма комитетының «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2013 елның 21 ноябрендәге 55 номерлы карары белән расланган Торак бинаны торак булмаган бинага һәм торак булмаган бинага күчерү өчен рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын;

гамәлдән чыккан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга : Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Котлы Бөкәш авылы, Совет урамы, 32 йорт; Тәберде Чаллысы авылы, Совет урамы, 34 йорт; Мәмле Казаклар

Чаллысы авылы, Үзәк урам, 29 йорт; Сатлыган авылы, Ленин урамы, 25а йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Котлы Бөкәш авыл җирлеге башлыгы Г.Г. Нәҗипов